ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЕНАБЕРДИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ ЕНАБЕРДИНО
ТОРАК ПУНКТЫНДА ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

КАРАР

13 ноябрь 2025 ел № 1

2026 елда Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Енабердино авыл җирлегенең Енабердино
авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 март 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлеге башлыгының “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлегенең Енабердино авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында” 2025 елның 1 ноябрендәге 5 нче номерлы карары нигезендә, 2025 елның 13 ноябрендә узган гражданнар җыены беркетмәсенә ярашлы: гражданнар җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 225 катнашучы, тавыш бирүдә катнашучылар саны 129 кеше кертелде.Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында 129 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0. Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлегенең Енабердино торак пунктында гражданнар җыены

Карар кылды:

1. Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлегенең Енабердино торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. “2026 елда Сез үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлегенең Енабердино авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I төркем инвалидлардан 500 сум күләмендә, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентларны, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын азат итеп, кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә ризамы?” дигән сорауга карар кабул ителгән дип санарга.

1) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (МТЗ-81 тракторы өчен тагылма сатып алу, үлән чабу)

2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Енабердино авылындагы юлларны кардан чистарту, узган елларның калган өлешләрен юлларны кардан чистартуга җибәрергә).

3) янгын куркынычсызлыгының беренчел чаралары белән тәэмин итү (1 данә янгынга каршы гидрант урнаштыру)»

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында

http://pravo.tatarstan.ru һәм www Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http:///mendsleevsk.tatarstan.ru “Енабердино авыл җирлеге” бүлегендә бастырып чыгарырга.

4. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Енабердино авыл җирлеге башлыгына әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Енабердино авыл җирлеге башлыгы Е.Ю.Скворцова